ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» сентябрь 2022 ел № 201

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2022-2023 еллар өчен җылылык чоры башлану турында.

2022-2023 елларның көзге-кышкы җылыту чоры башлануга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында " 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 12 сентябреннән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2022-2023 еллар өчен җылылык чоры башлануын билгеләргә.

2. «Таткоммунэнерго» РПО АҖ һәм ведомство котельныйлары булган оешма җитәкчеләренә 2022 елның 12 сентябреннән җылылык җибәрергә тәкъдим итәргә.

3. Инженерлык инфраструктурасы объектларының ышанычлы эшләвен тәэмин итү максаты белән торак-коммуналь предприятиеләр җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына авария очрагына җиһазлар һәм материаллар запасын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны “Татмедиа” АҖ филиалының Әгерҗе муниципаль районы “Әгерҗе хәбәрләре”(«Агрызские вести») газетасында бастырып чыгарырга һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә. Фатыйховка йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **Р.Р. Шәрипов**